**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№5359**
**07.10.2022**

Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4423 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир участокларын һәм шәхси милектәге җир участокларын яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 58-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда Россия Федерациясендә җир мөнәсәбәтләрен җайга салу үзенчәлекләре турында» 2022 елның 9 апрелендәге 629 номерлы карары, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4423 номерлы карары белән расланган муниципаль милектәге җирләрне һәм (яки) җир участокларын һәм шәхси милектәге җир участокларын яңадан бүлү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.4.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы – 22 эш көне.

Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы гариза теркәлгән көннән соң килгән көннән исәпләнә башлый.»;

2) 3.4.3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.4.3 Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, сорала торган документларны (мәгълүматларны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында белдерү кәгазьләре (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе) җибәрәләр.

Әгәр федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән булса, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлектән файдаланып муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документ һәм (яки) мәгълүмат бирү турында

ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрү срогы документны һәм мәгълүматны бирүче органга яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел (дәүләт кадастр исәбен алуны һәм (яки) күчемсез милек объектларына хокукларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашырганда – ике эш көне).

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар) яисә ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында белдерү кәгазе.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов